| | |
|---|---|
| **ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.11.2023 ел.** **Мәлки авылы** **№ 2**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Байморза авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Байморза авылы, Горький ур., 20 нче йорт адресы буенча урнашкан Байморза авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Байморза авылында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2023 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Байморза авылы, Горький урамы, 12 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Байморза авылында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Байморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:
*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*
- территорияне торак пунктның рөхсәтсез чүплекләреннән чистарту;
*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*
- материаллар алу белән су челтәрләрен ремонтлау;
-материаллар сатып алып, су күтәрү манарасын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- торак пунктлар чикләрендә материаллар сатып алып автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- материаллар сатып алып зиратны чистарту, төзекләндерү һәм ремонтлау.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге башлыгы Ф.П.Поляков